**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№1** **16.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Сукаеш авыл җирлеге составына керүче,
Курай Елга авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 25.1, 56 статьялары», Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы» нигезендә 16 ноябрь 2019 елда узган халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: «Сез 2020 елда Сукаеш авыл җирлеге Курай Елга торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә һәм 2 Төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкәннәрдән 150 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Курай Елга авылында “Дулкын чишмәсен” төзекләндерү (күперен, беседкасын ремонтлау);

« Әйе» « Юк».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 18 катнашучы кертелгән, җыенда катнашучылар саны 13 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 13 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге составына кергән Курай Елга авылында узган халык җыенын узды һәм халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Сез 2020 елда Сукаеш авыл җирлеге Курай Елга торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә һәм 2 Төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкәннәрдән 150 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Курай Елга авылында “Дулкын чишмәсен” төзекләндерү (күперен, беседкасын ремонтлау)

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Курай Елга авылы, Курай елга ур., 23 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен, җибәрергә.

Курай Елга авылы халык җыены рәисе,
Сукаеш авыл җирлеге башлыгы: З.Җ.Закирова